ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Гоголя, д.1, с.Акбаш, 423958

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Гоголь урамы, 1 йорт, Акбаш авылы, 423958

Тел./факс: (85593) 4-14-34, e-mail: Akbash.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 2** **15 февраль 2016 ел**

**Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга салучы законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның $43^{1}$ маддәсе, 2009 елның 9 февралендәге «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында»гы 14-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, 2015 елның 3 ноябрендәге «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәк булган авыл җирлекләреннән мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы 92-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы белән төзелгән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешү нигезендә, карар бирәм:

1. Муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге регламентына таянып эш итү барышында муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне җыю һәм аларны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгының 2016 елның 12 февралендәге 13 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрү буенча эш алып бару.
2. Район башкарма комитетына муниципаль норматив хокукый актларны, җирлек башлыкларын һәм авыл җирлеге башкарма комитетын җибәрү, шулай ук регистрга кертелергә тиешле белешмәләрне җирлек башкарма комитеты сәркатибен билгеләү өчен җаваплы.
3. Әлеге карарны Акбаш авылы, Мәктәп урамы, 17 нче йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга. www.yutaza.tatar.ru.
4. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Акбаш авыл җирлеге башлыгы: И. М. Миңнеханов

Башк.
Әхмәтова Ф. Р.
8 (85593) 4-14-34